

Регионыбызда олкән яшьтәге кешеләр халык санынын 28% тәшкил итә.
Халыкара олкәннәр коне - козге бәйрәм, ул ботен доньяда 1 октябрьдә билгеләп vтелә. Мордовиястат мәгълvматларына караганда, 2024 ел башына республикада 60 яшьтән олкәнрәк 217 365 кеше яшәгән, бу тобәк халкынын 28% тәшкил итә. Олкән яшьтәге кешеләрнен кvпчелеген хатын - кызлар - 63%.

Яше булуга карамастан, олкән буын гаиләләр тозvне дәвам итә. Әйтик, 2023 елда 60 яшь һәм аннан олкәнрәк 131 ир-ат һәм 89 хатын-кыз никахларын теркәгән.
Олкәннәр конен генә тvгел, декадасын, айлыкларын vткәрәләр. Шулай, Темников районы Тархан авылы администрациясе, клубы һәм



китапханә хезмәткәрләре Олкәннәр айлыгы кысаларында авылнын хормәтле олылары очен тvгәрәк остәл артында “Чәй эчv” чарасы оештырган. Чәй эчv - кvнелле вакыт vткәрv, ул аралашу һәм ял итv очен бик яхшы сәбәп. Бигрәк тә табын янында кунаклар кvп булганда. Чара яхшы, дустанә шартларда котлаулар, истәлекләр һәм кvнелле аралашулар гармунга койләп жырлаулар белән vрелеп барган. Алар сәламәтлек, бәхет, мәрхәмәт һәм тынычлык теләп таралыштылар.

Олкәннәр коне - ул бәйрәм генә тvгел, ә илнен киләчәк буынын тәрбияләv эшенә, һонәренә жанын салган кешеләргә хормәт кvрсәтv момкинлеге дә. Шулай, Мордовия мәктәп укучылары да ветераннарны искә алу һәм кайгыртуны белдереп открыткалар, чәчәкләр бvләк итv акциясендә катнашалар, алар белән торле темаларга әнгәмә тоталар; мәдәниятыбызнын, тормышыбызнын мо-һим олеше булуын кvрсәтәләр. Мондый чаралар буыннар арасындагы элемтәне ныгыта һәм безгә кешелек монәсәбәтләренен әһәмиятен искә тоше-рә.



Рузаевка районы Татар Пешлә авылында да олкәннәрне хормәт итv гадәттә. Авыл мәктәбендә торле чаралар vтеп килә, ә Мәдәният йорты житәкчесе Наталья Анатольевна Чалдаева бу декадник турында болай ди: “Олкәннәр коне -ул якты һәм кvркәм бәйрәм; без олкән буынны һәрвакыт кайгыртабыз һәм игътибар белән чолгап алабыз. Олкәннәр унконлеге кысаларында 5 октябрьдә Татар Пишләсе авылында “Ә тормыш һәрвакыт матур булып кала!” акциясен vткәрдек. Авыл урамнарында олкәннәрне котладык һәм олыларнын кvнелләренә шатлык остәдек.
Без олкән буынны хәтерлибез һәм хормәт итәбез. Олкәннәр яхшы сvзгә, игътибарга һәм кайгыртуга мохтаж.”